**Әтиемә**

1) Мин әтиемә охшаган,
   Аның иркә кызчыгы.
   Мин әтинең горурлыгы
   Яраткан йолдызчыгы.

Кушымта:
   Әтиемне бик яратамын,
   Ул да мин дип җан ата.
   Аңа багышлап бу җырны яздым,
   Өзелеп яратканга.

2) Әти минем таянычым,
   Ярдәм итә һәр囲 эштә.
   Ул мине гел яклаучы да,
   Саклаучы да фәрештә.

3) Энем белән әтиемнең
   Кочагыннан төшмибез.
   Әни белән икесенә
   Озын гомер телибез.